РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**27.04.2021** Кукмара ш. **№ 344**

Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының хисап нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында карар **бирәм:**

1. Торак урын мәйданының хисап нормасын, шуннан чыгып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында, гражданнарның гомуми торак урыны белән тәэмин ителү дәрәҗәсе билгеләнә, гаиләнең бер әгъзасына торак урынының гомуми мәйданы 18 кв. метрдан артмаган күләмдә билгеләргә.

2. Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданын бирү нормасын, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бер гражданга торак урынының гомуми мәйданын 18 кв. метр күләмдә билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**